ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2026 ел Баулы шәһәре № 80

2026-2029 елларга Баулы муниципаль районы муниципаль финансларын җайлау буенча чаралар планын раслау турында

Баулы муниципаль районы бюджеты балансын тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- 2026-2029 елларга Баулы муниципаль районы муниципаль финансларын җайлау буенча чаралар планы;
- 2026-2029 елларга Баулы муниципаль районы муниципаль финансларын җайлау буенча чаралар планын гамәлгә ашу нәтиҗәсендә Баулы муниципаль районы бюджетының бюджет эффектын бәяләү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 24 июлендәге
80 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2026 – 2029 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль финансларын җайлау чаралары планы

| № т/б | Чараның атамасы | Башкару өчен җаваплы затлар | Башкару вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1.1. | Баулы муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрү, аның нәтиҗәләре буенча кирәк булганда аерым салым ташламаларын һәм киметелгән салым ставкаларын юкка чыгару турында карар кабул ителү | Җирле үзидарә органнары, Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 2026-2029 еллар |
| 1.2. | Салымнар һәм җыемнар, Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына (җирле бюджетларга) аренда түләүләре буенча бурычларны (недоимкаларны) киметү буенча оешмалар белән, шулай ук узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда салым түләүләрен киметкән оешмалар белән кирәкле эш башкару | Үз керемнәрен үстерү буенча ведомствоара комиссия, Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ | 2026-2029 еллар |
| 1.2.1. | Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салым түләүләрен киметкән, шулай ук барлык дәрәҗәдәге бюджетларга түләүләр буенча бурычлары булган оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген карау буенча баланс комиссияләре үткәрү | Үз керемнәрен үстерү буенча ведомствоара комиссия, Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы | квартал саен |
| 1.2.2. | Оешмалар буенча физик затлар керемнәренә салым | Җирле үзидарә органнары, Баулы | квартал саен |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | керемнәре мониторингын, узган елның шушы чорына карата физик затлар керемнәренә салым керемнәрен киметкән салым түләүчеләр мониторингын муниципаль берәмлекләр буенча үткәрү | муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 16 номерлы районара инспекциясе (килешү буенча) | |
| 1.2.3. | Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына керә торган салымнар һәм җыемнар буенча Баулы муниципаль районы муниципаль берәмлекләре буенча бурычларга мониторинг үткәрү һәм күрсәтелгән бурычны киметүгә юнәлдерелгән чаралар күрү | Җирле үзидарә органнары, Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 16 номерлы районара инспекциясе (килешү буенча) | ай саен |
| 1.2.4. | Дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча бурычлары булган оешмалар һәм физик затлар белән тиешле эш алып бару | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, җирле үзидарә органнары | ай саен |
| 1.2.5. | Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары администрацияли торган түләүләр буенча срогы чыккан дебитор бурычларына мониторинг үткәрү, шулай ук дәгъва-дәгъва эшенең сыйфатын яхшырту | Җирле үзидарә органнары, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ | квартал саен |
| 1.2.6. | Җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр, эре предприятиеләр хезмәткәрләренең мөлкәт салымнары буенча бурычларын каплау чараларын үткәрү | Җирле үзидарә органнары, Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 16 номерлы районара инспекциясе (килешү буенча) | 2026-2029 еллар |
| 1.2.7. | Физик затларның милек салымнарын мобилизацияләү буенча чаралар үткәрү | Җирле үзидарә органнары, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 16 номерлы районара инспекциясе (килешү буенча), Баулы муниципаль | 2026-2029 еллар |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | районы финанс-бюджет палатасы | |
| 1.3. | Күләгәдәге мәшгульлекне легальләштерү һәм гражданнар керемнәренә салым салу буенча чаралар күрү | Үз керемнәреңне үстерү буенча ведомствоара комиссия (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге) | 2026-2029 еллар |
| 2.1. | Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешен тиешле финанс елына һәм план чорына фаразлау буенча сценарий шартлары нигезендә Баулы муниципаль районы бюджеты проектын төзү | Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасы, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге | 2026-2029 еллар |
| 2.2. | Муниципаль милекне нәтиҗәле куллану максатында тәмамланмаган төзелеш күләмнәре үсешен булдырмау | Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары | 2026-2029 еллар |
| 2.3. | Бюджет челтәре эффективлыгын күтәрү һәм оптимизацияләү | | |
| 2.3.1. | Нәтиҗәсез эшләгән муниципаль учреждениеләрне ачыклау, учреждениеләрне бетерү яки кабаттан оештыру турында тәкъдимнәр әзерләү, һәм шулай ук (нәтиҗәлелекне исәпкә алып һәм бюджет чыгымнарын оптимизацияләү максатында) муниципаль учреждениеләр булмаган оешмаларны муниципаль хезмәтләр күрсәтү процессына кертү мөмкинлеген карау | Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары | 2026-2029 еллар |
| 2.4. | Коммерцияле булмаган оешмаларга һәм юридик затларга ярдәм чаралары (субсидияләр) бирүнең нәтиҗәлелеген һәм бюджет чыгымнарын оптимизацияләү максатында анализлау | Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары | 2026-2029 еллар |

---

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 24 июлендәге
80 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2026-2029 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының муниципаль финансларын җайлау чаралары планын гамәлгә ашырудан Баулы муниципаль районының бюджет нәтиҗәлеген бәяләү

| Чараның атамасы | Бюджет эффектын бәяләү, мең сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел |
| 1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджеты керемнәрен арттыру буенча чаралар:<br>- Баулы муниципаль районы бюджетына салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны киметү чараларын үткәрү | 2657,6 | 2700,0 | 2803,0 | 2900,0 |
| 2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджеты чыгымнарын оптимизацияләү буенча чаралар:<br>- мәгариф учреждениеләрендә укучылар контингенты кимүгә бәйле рәвештә штат берәмлекләрен кыскарту | 1078,5 | 1121,6 | 1166,5 | 1213,2 |